Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Яңа Никольский авыл Советы

КАРАР

26 октябрь 2023 ел №74

Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Яңа Никольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 29 октябрендәге 21 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 19 октябрендәге 02-08-02/1071 номерлы күрсәтмәсен карап

Яңа Никольский авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Яңа Никольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 29 октябрендәге 21 номерлы карарының 1 нче кушымтасына (Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл Советының 2022 елның 25 февралендәге 33 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 44 номерлы, 2023 елның 19 маендагы 64 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяда:

а) җиденче абзацка «билгеләнә» сүзеннән соң «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 18 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары нигезләмәләрен исәпкә алып» сүзләрен өстәргә;

б) сигезенче абзацка «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 18 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары нигезләмәләрен исәпкә алып» сүзләрен өстәргә;

1.2. 11 статьяның 13 пунктының беренче абзацында «шәраб материаллары» сүзеннән соң «шикәрле эчемлекләр» сүзләрен өстәргә;

1.3. 24.1 статьяның 1 пунктында «һәм аларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 25 статьяның 2 пунктында:

а) беренче абзацта «программаны раслаган башкарма комитет карары нигезендә» сүзләрен «башкарма комитет билгеләгән муниципаль

программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «билгеләнгән срокларда» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) өченче абзацта «үз көченә кергән көннән алып өч ай» сүзләрен «агымдагы финанс елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 26 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Яңа Никольский авылы, Үзәк урам, .45 йорт, Салкын Алан авылы,Луговая урамы, 60 йорт, Иштирәк авылы, Чишмә урамы, 3 йорт, Сосновка, Хазовка авыллары территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы өстенә йөкләргә.

Яңа Никольский авыл җирлеге
башлыгы вазыйфаларын башкаручы

К. Е. Тарасов